| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** | **СОВЕТ НИЖНЕКУЮКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |

422741 Республика Татарстан Атнинский район с. Нижний Куюк. Тел. 3-32-47

КАРАР

«19» октябрь 2022 ел №3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер
торак пунктында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 30.10.2022 ел Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 30 октябрь 2022 ел 11.00 сәг. тән 12.00 сәг. кадәр;
- үткәрү урыны – Яңа Шимбер авылы, Тукай ур., 26 йорт янында.

1.3. Татарстан республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
- 2022 елның 25 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Көек авылы, Татарстан урамы, 71 а йорты;
- сайлау хокукына ия булган Яңа Шимбер торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Яңа Шимбер торак пункты халкына гражданнар җыены турында мәгълүматны мәгълүмати стендлар аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәьәләне расларга:

Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Яңа Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- агач һәм куакларны кисү, үсентеләрне һәм чүп-чарны чистарту килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- Яңа Шимбер авылы урамнарын кардан чистарту (эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Яңа Шимбер авылы зиратына юлларны ремонтлау һәм каплау өчен төзелеш материаллары сатып алу, ташу, җәю, эш һәм хезмәтләр өчен түләү мәсьәләләрен кабул итәргә.

"РИЗА" "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында "Интернет" мәълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Көек авылы, Татарстан ур., 71 а йорты, Түбән Көек башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Д.М. Галиәхмәтов